ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**
**“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 24 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяның 8 өлешендә “ябык” сүзен “гавами булмаган” сүзләренә алмаштырырга;

2) 15 статьяның 1 өлешендәге 20 пунктына “, индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзүне яки реконструкцияләүне планлаштыру турында хәбәрнамәдә (алга таба – планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамә) күрсәтелгән параметрлары билгеләнгән параметрларга туры килү һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруны рөхсәт итү турында хәбәрнамә, индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрлары билгеләнгән параметрларга туры килмәү һәм (яисә) индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруны рөхсәт итмәү турында хәбәрнамә, индивидуаль торак төзелеше объектлары яисә бакча йортлары җирлекләр территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрендә

төзелгәндә яисә реконструкцияләнгәндә, төзелгән яисә реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге хакындагы законнар таләпләренә туры килүе яисә туры килмәве турында хәбәрнамә юллау, Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү турында карар, үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү яисә аны рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында билгеләнгән чик параметрларына яисә капиталь төзелеш объектларының федераль законнарда билгеләнгән параметрларына карата мәҗбүри таләпләргә туры китерү турында (алга таба шулай ук – билгеләнгән таләпләргә туры китерү) карар, максатчан билгеләнештә файдаланмый торган яисә Россия Федерациясе законнарын бозып файдалана торган җир кишәрлеген тартып алу турында карар кабул итү, үз белдеге белән төзелгән корылманы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда җимерүне яисә аны билгеләнгән таләпләргә туры китерүне гамәлгә ашыру" сүзләрен өстәргә;

3) $15^1$ статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 17 пункт өстәргә:

"17) "Кулланучылар хокукларын яклау турында" 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру.";

4) $16^1$ статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 15 пункт өстәргә:

"15) "Кулланучылар хокукларын яклау турында" 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру.";

5) 17 статьяның 1 өлешендәге 26 пунктына ", индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрлары билгеләнгән параметрларга туры килү һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруны рөхсәт итү турында хәбәрнамә, индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрлары билгеләнгән параметрларга туры килмәү һәм (яисә) индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруны рөхсәт итмәү турында хәбәрнамә, индивидуаль торак төзелеше объектлары яисә бакча йортлары шәһәр округлары территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрендә төзелгәндә яисә реконструкцияләнгәндә, төзелгән яисә реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге хакындагы законнар таләпләренә туры килүе яисә туры килмәве турында хәбәрнамә юллау, Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү турында карар, үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү яисә аны билгеләнгән таләпләргә

туры китерү турында карар, максатчан билгеләнештә файдаланмый торган яисә Россия Федерациясе законнарын бозып файдалана торган җир кишәрлеген тартып алу турында карар кабул итү, үз белдеге белән төзелгән корылманы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда җимерүне яисә аны билгеләнгән таләпләргә туры китерүне гамәлгә ашыру" сүзләрен өстәргә;

6) 17[1] статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 18 пункт өстәргә:

"18) "Кулланучылар хокукларын яклау турында" 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 06 октябрь
№ 65-ТРЗ